| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ЭБАЛАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 10 нчы октябере Ябалак авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Кайбыч авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 21 октябрендә 12 сәгать 30 минутка Кече Кайбыч авылы,Мәктәп урамы,10А адресы буенча урнашкан башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Кече Кайбыч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 22 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы,Үзәк урамы,52 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гранданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3 2019 елның 22 октябрендә 15 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы, Үзәк урамы, 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гранданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2019 елның 23 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы, Урман урамы,4 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча граҗданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Ябалак авыл җирлеге Кече Кайбыч авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- материаллар сатып алып, ритуаль хезмәтләр күрсәтү бинасын төзү;;
- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм ремонтлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.